ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
2016 елның 25 феврале

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№ 03-03-415

2016-2026 елларга «Ишегалды стандарты» муниципаль программасы турында

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре Советының 2015 елның 23 декабрендәге 31 нче номерлы карарын үтәү йөзеннән, шулай ук тулы ял итү өчен уңайлы шартлар тудыру, даими яшәү урынына якын территорияләрдә халыкның югары көнкүреш мәдәниятен формалаштыру, аның төзекләндерүдә һәм ишегалды территорияләрендә тәртипне саклауда катнашуы аша халыкның актив гражданлык позициясен формалаштыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

2016-2026 елларга «Ишегалды стандарты» муниципаль программасын (1 нче, 2 нче кушымта) расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның «25» февралендәге
03-03-415 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2016-2026 елларга "ИШЕГАЛДЫ СТАНДАРТ"**
**МУНИЦИПАЛЬ АДРЕСЛЫ ПРОГРАММА.**

## МУНИЦИПАЛЬ АДРЕСЛЫ ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2016-2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль адреслы программа |
| Заказ бирүче | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» МБУ |
| Максат һәм бурычлар | «Ишегалды стандарты» программасы асфальт өслеген ремонтлауны, заманча архитектур формалар белән ишегалды мәйданчыкларын төзекләндереп куюны күздә тота. Балалар мәйданчыклары җиһазы, балалар өчен хыял дөньясы тудырырга, балаларның акыл, физик сәләтләрен үстерергә тиеш. Урта һәм өлкән яшьтәге халык өчен ишегалды ял итү зонасы буларак карала. |
| Тормышка ашыру вакыты | 2016-2026 еллар |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2016-2026 елларда программа чаралары системасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанслауның гомуми күләме 367 550 мең сум тәшкил итә.<br>Финанслау чыганаклары:<br>Зеленодольск муниципаль районы бюджеты һәм финанслауның башка чыганаклары |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Ишегалды территорияләрендә шартлар булдыру, кешенең психологик халәтенә уңай йогынты ясаучы, торак төзелешенең архитектур йөзен яхшырту. Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләрнең сәламәт ялын һәм яшәү шартларын тәэмин итү, шәһәр халкының яшәү шартларын яхшырту. Халыкны күпфатирлы йортлар белән идарә итүгә җәлеп итү. Төзекләндерү объектларына халыкның җаваплылыгын арттыру. Социаль тулай торак формалаштыру. Ишегалларында парковка проблемаларын хәл итү. |

| | |
|---|---|
| Контроль оештыру системасы | Программаны тормышка ашыруны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты контрольдә тота. |

**1.Программалы метод белән хәл итүнең эчтәлеге, проблемалары һәм кирәклеген нигезләү.**

**.**

2016 - 2026 елларга «Ишегалды стандарты» муниципаль программасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы А.В. Тыгин йөкләмәсе нигезендә эшләнгән.

Шәһәр микрорайоннарын төзүне планлаштыруда йортларның үзәге-ишегалды территориясе булган торак төркемен формалаштыру мөһим урын алып тора. Билгеле, ишегалды территориясе, аның торышы, төзекләндерү дәрәҗәсе һәрвакытта да норматив таләпләрне канәгатьләндерми. Объектив сәбәпләр аркасында соңгы елларда ишегалды территорияләрен төзекләндерү, асфальт өслеген ремонтлау, яшелләндерү, яңа архитектура формаларын урнаштыру зур әһәмияткә бирелмәде.

Зеленодольск шәһәрендә квартал эчендәге территорияләрне төзекләндерү буенча проблемалар бар, аларга җирле үзидарә органнары тарафыннан игътибар җитәрлек дәрәҗәдә бирелмәгән.

Ишегалды территорияләрен заманча уңайлыклар нормаларына китерү өчен әлеге Программаны кабул итү зарурлыгы туды, анда ишегалды һәм квартал эчендәге территорияләрне комплекслы төзекләндерү буенча максатчан эш, шулай ук Зеленодольск шәһәре күпфатирлы йортлары ишегалларында парковка урыннарын билгеләү каралган.

**2.Программаның төп максатлары һәм бурычлары, гамәлгә ашыру вакытлары.**

2016 - 2026 елларга «Ишегалды стандарты» муниципаль программасы асфальт өслеген ремонтлауны, ишегалды мәйданчыкларын төзекләндерүне, заманча архитектура формаларын урнаштыра. Балалар мәйданчыклары җиһазы, балалар өчен хыял дөньясы тудырырга, балаларның акыл, физик сәләтләрен үстерергә тиеш. Урта һәм өлкән яшьтәге халык өчен ишегалды ял итү зонасы буларак карала.

Программаны тормышка ашыру Зеленодольск шәһәренең архитектура-сәнгать күренешен тагын да тулыландырырга һәм баетырга мөмкинлек бирәчәк.

Программа түбәндәге төп бурычларны үтәүгә юнәлдерелгән:

- Кварталара юллардагы һәм ишегалды территорияләрендәге асфальт өслеген ремонтлау яки реконструкцияләү (Зеленодольск муниципаль районы бюджеты хисабына).
- Автотранспортның парковка урыннарын чикләү һәм төзекләндерү.

- Хәзерге заман архитектура формаларын, балалар, спорт мәйданчыкларын һәм ял итү урыннарын урнаштырган ишегалды мәйданчыкларын (күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре акчалары исәбеннән) төзекләндерү.
- Халыкны күпфатирлы йортлар белән идарә итүгә җәлеп итү.

## 3.Программаның төп юнәлешләре.

Программа башка программалар һәм чаралар белән үзара бәйләнештә гамәлгә ашырыла, алар кысаларында инфраструктура үзгәрешләре, Зеленодольск шәһәрен үстерү буенча конкрет проектлар тормышка ашырыла.

Ишегалды территорияләрен комплексы төзекләндерү кече архитектура рәвешләрен, асфальт өслекләрен, йорт яны территорияләрен саклап калу һәм яңарту өлкәсендә төп юнәлеш булып тора.

Халык ялы өчен шартлар тудыру, аларның физик сәламәтлеген һәм физиологик сәләтләрен үстерү өлкәсендә төп юнәлеш ишегалды мәйданчыкларын комплексы төзекләндерү.

## 4. Программаны ресурслар белән тәэмин итү.

Программаны финанслау җирле бюджет акчалары, шулай ук башка финанслау чыганаклары хисабына гамәлгә ашырыла.

Программаны финанслау күләме ел саен билгеләнә.

Программаны тормышка ашыруга сарыф ителә торган акчалар бюджет финанславы мөмкинлекләреннән чыгып ачыклана.

Бер елга Программаны финанслауның якынча күләме 36755 мең сум тәшкил итә.

Аны гамәлгә ашыруның бөтен чорында финанслау күләме якынча 367 550 мең сум тәшкил итә.

Әлеге программаны гамәлгә ашыруда күпфатирлы йортларның йорт яны территорияләрен асфальтлаштыру эшләрен башкару күздә тотыла, аларда биналар милекчеләре гомуми җыелышында билгеләнгән тәртиптә әлеге территорияләрне зоналарга бүлү турында, шулай ук аларда төзекләндерү объектлары составы турында карар кабул итте.

## 5.Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге.

Программа гражданнарның мәнфәгатьләрен күздә тотып, өстәмә комплексы төзекләндерелгән ишегалды территорияләрен булдыру зарурлыгыннан чыгып эшләнгән. Әлеге программаның икътисади нәтиҗәлелеге зур булмаган күрсәткечләргә ия, нигездә, программада социаль күрсәткечләрне һәм индикаторларны яхшырту хас. Программаның социаль нәтиҗәлелеге түбәндәгеләр исәбеннән ирешелә:

- ишегалды территорияләренең санитар торышын яхшырту;
- ишегалды төзелешенең архитектур йөзен яхшырту;
- Зеленодольск шәһәренең урта һәм өлкән яшьтәге халкының ялы өчен шартлар тудыру;
- балалар һәм яшьләр өчен физик сәләтләрне үстерү һәм сәламәтлекне ныгыту өчен шартлар тудыру;
- экологик хәлне яхшырту;
- инженерлык инфраструктурасын яңарту һәм киңәйтү;
- халыкка торак-коммуналь хезмәт күрсәтүнең сыйфатын күтәрү.

Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре түбәндәгеләр:
- ишегалды территорияләрендә кешенең психологик халәтенә уңай йогынты ясый торган шартлар формалаштыру,
- торак төзелешенең архитектур йөзен яхшырту,
- Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләр өчен сәламәт шартлар тәэмин итү,
- яшәү шартларын яхшырту,
- халыкны күпфатирлы йортлар белән идарә итүгә җәлеп итү,
- төзекләндерү объектлары өчен халыкның җаваплылыгын арттыру,
- ишегалларында шәхси автотранспортны кую проблемаларын хәл итү.

## 6. Программа белән идарә итү һәм аны гамәлгә ашыруның барышын тикшереп тору

Программаны гамәлгә ашыруның барышын гомуми җитәкчелек һәм тикшереп торуны Программаның муниципаль заказчысы - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра. Программаның координацияләү һәм оператив контроль үтәлеше “Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты” МБУна йөкләнә.

## 7. Күпфатирлы йортларны Программага кертү шартлары

Программага Зеленодольск шәһәре территориясендә урнашкан барлык күпфатирлы йортлар кертелә, аларның йорт яны территорияләре норматив-хокукый актлар таләпләре нигезендә асфальт өслеген торгызу (ремонтлау, урнаштыру) эшләренә мохтаҗ.

Эшләрне үткәрү чираты әлеге программада күрсәтелгән критерийлар нигезендә билгеләнә.

## 8. Эшләр башкару өчен күпфатирлы йортларның чиратын билгеләү критерийлары

1. Беренче чиратта программаны гамәлгә ашыру 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү

фонды турында» Федераль закон нигезендә комплекслы капиталь ремонт ясалган күпфатирлы йортлар өчен каралган. Йортларның әлеге төркем эчендә күпфатирлы йортларның чираты гомуми тәртиптә исәпләнгән сан рейтингы зурлыгы нигезендә формалаштырылган.

2. Икенче чиратта программаны гамәлгә ашыру беренче чиратка кертелмәгән башка күпфатирлы йортлар өчен каралган. Чират Программага кертелгән һәр күпфатирлы йортка индивидуаль сан рейтингын түбәндәге формула буенча бирү юлы белән билгеләнә:

Р = (Ф / Ж )* Д * А * И * С * К,  кайда:

Р-санлы рейтинг зурлыгы,

Ф-бюджет акчалары хисабына программа чараларын гамәлгә ашыруны финанслауның кирәкле суммасы(сумнарда),

Ж-күп фатирлы йортта яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар саны-1 кеше),

Д - күпфатирлы йорттагы (кв.м)  биналарның гомуми мәйданына бүленгән күпфатирлы йорттагы (сумнарда) торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычларның гомуми суммасын (сумнарда) бүлү һәм нәтиҗәне 100гә бүлү юлы белән алынган бурыч коэффициенты, аннан соңгы  якындагы санга кадәр зур якка түгәрәкләндерү.

А - гомуми җыелышта карар кабул иткәндә милекчеләр активлыгының коэффициенты, ул милекчеләрнең гомуми җыелышында тавышларның процент санын милекчеләрнең гомуми җыелышында 100гә бүлү нәтиҗәсе буларак билгеләнә, аннан соңгы  унынчы берәмлеккә кадәр зур якка түгәрәкләндерелә.

И - социаль интеграция коэффициенты. Әгәр күпфатирлы йорттагы биналар милекчеләре региональ оператор исәбендә капиталь ремонт фонды формалаштырсалар, И=0,5, әгәр махсус исәптә булса, И=1.

С - аңлылык коэффициенты. Әгәр күпфатирлы йортта күпфатирлы йорт советы сайланса, С=0,5, күпфатирлы йортта күпфатирлы йорт советы сайланмаса, С=1

К - коммуникацияләр коэффициенты. Әгәр күпфатирлы йортка карата хисап бирү (җылылык сезонына әзерлек, запрослар, мәгълүмат ачу һ.б.) буенча җирле үзидарә органнарының кисәтүләре булмаса, шулай ук күпфатирлы йорт вәкилләре җирле үзидарә органнары үткәрә торган чараларда (киңәшмәләрдә, семинарларда, очрашулар һ. б.) даими катнашучылар булып торалар И=0,5, башкача (ТР ЭТИС өчен үз вакытында чагыштыру актларын тапшырмау һ. б.) И=1.

Күпфатирлы йортларның чиратлылыгы рейтингның минималь күрсәткечләреннән максималь күрсәткечләргә нисбәте буенча (ягъни сан күрсәткече азрак булган саен, Программа нигезендә эшләр шулкадәр алданрак башкарыла) сортировкалау юлы белән билгеләнә.

**9. Программаны гамәлгә ашыру механизмы**

1. Асфальт өслеген ремонтлау (торгызу, урнаштыру) буенча эшләр Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән ел саен

раслана торган программаны тормышка ашыру планы (алга таба - текст буенча- еллык План) нигезендә башкарыла. Ел саен Планга программаны тормышка ашыруның чираттагы елына финанслау лимиты кысаларында, план раслану датасына кадәр булган айның соңгы числосына формалаштырылган, аларның чираты нигезендә, күпфатирлы йортлар кертелә.

Еллык Планга күпфатирлы йортлар керә, аларга Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты адресына карата Планны раслау датасына кадәрге айның соңгы көненә Программада катнашу турында күпфатирлы йортлардагы биналар милекчеләренең (алга таба текст буенча - Мөрәҗәгатьләр) мөрәҗәгать итүләре, Программага кертелгән йортлар санынннан кергән.

2. Мөрәҗәгатьтә күпфатирлы йортны еллык Планга кертүгә ачыктан-ачык ризалык булырга тиеш. Мөрәҗәгатькә күпфатирлы йортның йорт яны территориясен зоналаштыру планы расланган күпфатирлы йорттагы биналар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе (Зеленодольск шәһәрен территориаль планлаштыру документлары нигезендә) беркетелергә тиеш, шулай ук милекчеләрнең еллык Планга кертүгә, шулай ук әлеге карар белән расланган зоналарга ризалыгы белдерелергә тиеш. Әлеге беркетмәдә шулай ук йорт яны территориясен төзекләндерү эшләрен башкару кирәклеге турындагы мәсьәлә буенча милекчеләрнең ачыктан-ачык чагылдырылган карары яисә түбәндәге элементларга карата мондый ихтыяҗ булмау турында карар булырга тиеш:

- Кече яшьтәге балаларның уеннар мәйданчыгы.
- Өлкән яшьтәге халык өчен ял мәйданчыгы.
- Физкультура белән шөгыльләнү мәйданчыгы.
- Хуҗалык максатлары өчен мәйданчык (кер киптерү һәм келәмнәрне алу).
- Этләрне йөртер өчен мәйданчык.
- Йорт яны территориясен яктырту.
- Йорт яны территориясен яшелләндерү.
- Җир өсте суларын йорт яны территориясеннән чыгару.
- Подъездларга керү.
- Чүп контейнерлары өчен мәйданчыклар.

Милекчеләр атап үтелгән ихтыяҗ турында карар кабул иткән очракта, беркетмәдә йорт яны территориясен төзекләндерү эшләре составына, күләменә, вакытларына, бәясенә карата күпфатирлы йорттагы биналар милекчеләре акчалары исәбеннән, әлеге эшләрне финанслау шартлары, тәртибе һәм вакытлары исәбеннән кабул ителгән карарлар турында белешмәләр булырга тиеш.

Документлар күпфатирлы йорт Советы рәисе имзасы яисә күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең вәкаләтле вазыйфаи заты (яисә торак, торак-төзелеш кооперативы) тарафыннан таныкланырга тиеш. Беркетмә гамәлдәге законнар таләпләренә туры килергә тиеш.

3. Еллык Планны финанслау лимитлары Мөрәҗәгатьләр булган барлык күпфатирлы йортларга карата Программаны гамәлгә ашыру эшләрен башкарырга мөмкинлек бирмәгән очракта, Планга Мөрәҗәгатьләр булган йортлар саныннан рейтингның иң зур күрсәткече булган күпфатирлы йортлар

кертелми. Бу очракта мондый йортны киләсе ел планына кертү мөмкинлеге, гомуми тәртиптә санлы рейтинг күләменнән чыгып, яңа формалаштырыла торган чират белән билгеләнә.

4. Әлеге Программаны гамәлгә ашыру кысаларында эшләр муниципаль контрактлар нигезендә башкарыла, аларда «ТР ЗМР төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ заказчы буларак чыгыш ясый.

|  | Адрес | Капремонт |  | S (мәйдан) | ₽(сумма) | Ф/Ж | коэффициент Д | коэффициент А | коэффициент И | коэффициент С | коэффициент К | рейтинг Р |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Комаров, 18 йорт | 1 | **** | 256 | 640000,00 | 2057,88 | 1,00 |  | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 514,47 |
| 2 | Комаров, 15 йорт | 1 | **** | 356 | 890000,00 | 2079,44 | 1,00 |  | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 519,86 |
| 3 | К.Маркс, 56 йорт | 1 | ** | 770 | 1925000,00 | 11000,00 | 1,00 |  | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 2750,00 |
| 4 | К.Маркс, 57 йорт | 1 | ** | 1050 | 2625000,00 | 11075,95 | 1,00 |  | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 2768,99 |
| 5 | Хаҗиев, 8 йорт | 1 | *** | 1472,00 | 3680000,00 | 11645,57 | 1,00 |  | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 2911,39 |
| 6 | Кече Кызыл,  9 йорт | 1 | *** | 460 | 1150000,00 | 6284,15 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 3142,08 |
| 7 | Норкин, 9 йорт | 1 | *** | 510 | 1275000,00 | 6929,35 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 3464,67 |
| 8 | Гоголь, 42 йорт | 1 | ** | 520 | 1300000,00 | 7344,63 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 3672,32 |
| 9 | Украина, 7 йорт | 1 | *** | 700 | 1750000,00 | 7954,55 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 3977,27 |
| 10 | Кече Кызыл,  7 йорт | 1 | **** | 560 | 1400000,00 | 8333,33 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 4166,67 |
| 11 | Фрунзе,18 йорт | 1 | *** | 610 | 1525000,00 | 8567,42 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 4283,71 |
| 12 | Төньяк,  3 йорт | 1 | *** | 510 | 1275000,00 | 8916,08 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 4458,04 |
| 13 | Фрунзе, 12 йорт | 1 | *** | 660 | 1650000,00 | 9821,43 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 4910,71 |
| 14 | Энгельс, 13 йорт | 1 | ** | 740 | 1850000,00 | 10054,35 | 2,00 |  | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 5027,17 |
| 15 | Фрунзе, 5 йорт | 1 | ** | 784 | 1960000,00 | 10537,63 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 5268,82 |
| 16 | Засорин, 10 йорт | 1 | *** | 450 | 1125000,00 | 5306,60 | 2,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 5306,60 |
| 17 | Фрунзе, 13 йорт | 1 | ** | 630 | 1575000,00 | 10787,67 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 5393,84 |
| 18 | Ленин, 15 йорт | 1 | **** | 360 | 900000,00 | 11538,46 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 5769,23 |
| 19 | Энгельс, 36 йорт | 1 | ** | 715 | 1787500,00 | 23519,74 | 1,00 |  | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 5879,93 |
| 20 | Ленин, 32 йорт | 1 | *** | 1064 | 2660000,00 | 11928,25 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 5964,13 |
| 21 | К.Маркс, 50 йорт | 1 | * | 710 | 1775000,00 | 11993,24 | 2,00 |  | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 5996,62 |
| 22 | Тургенев, 2 йорт | 1 | *** | 1090 | 2725000,00 | 12219,73 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 6109,87 |
| 23 | Фрунзе, 14 йорт | 1 | *** | 835 | 2087500,00 | 13381,41 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 6690,71 |
| 24 | Украина, 27 йорт | 1 | ** | 490 | 1225000,00 | 28488,37 | 1,00 |  | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 7122,09 |
| 25 | Комсомол, 8 йорт | 1 | **** | 650 | 1625000,00 | 14639,64 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 7319,82 |
| 26 | Рогачев, 1 йорт | 1 | *** | 930 | 2325000,00 | 15196,08 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 7598,04 |
| 27 | Космонавтлар, 9 йорт | 1 | * | 680 | 1700000,00 | 32075,47 | 1,00 |  | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 8018,87 |
| 28 | Татарстан, 20 йорт | 1 | ** | 640 | 1600000,00 | 16326,53 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 8163,27 |
| 29 | Ленин, 64 йорт | 1 | ** | 795 | 1987500,00 | 16425,62 | 1,00 |  | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 8212,81 |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 30 | Ленин, 35 йорт | 1 | *** | 1372 | 3430000,00 | 18244,68 | 1,00 | | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 9122,34 |
| 31 | Ленин, 31 йорт | 1 | *** | 1308 | 3270000,00 | 36741,57 | 1,00 | | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 9185,39 |
| 32 | Украина, 3 йорт | 1 | *** | 1680 | 4200000,00 | 19444,44 | 2,00 | | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 9722,22 |
| 33 | Ленин, 27 йорт | 1 | **** | 1060 | 2650000,00 | 20542,64 | 2,00 | | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 10271,32 |
| 34 | Энгельс, 11 йорт | 1 | **** | 1380 | 3450000,00 | 22258,06 | 2,00 | | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 11129,03 |
| 35 | Украина, д. 5 йорт | 1 | **** | 990 | 2475000,00 | 11565,42 | 2,00 | | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 11565,42 |
| 36 | К.Маркс, 42/8 йорт | 1 | * | 610 | 1525000,00 | 11914,06 | 2,00 | | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 11914,06 |
| 37 | Космонавтлар, 7 йорт | 1 | ** | 710 | 1775000,00 | 25000,00 | 2,00 | | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 12500,00 |
| 38 | Энгельс, 23 йорт | 1 | *** | 1404 | 3510000,00 | 25808,82 | 1,00 | | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 12904,41 |
| 39 | Комсомол, 6 йорт | 1 | *** | 1405 | 3512500,00 | 25827,21 | 1,00 | | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 12913,60 |
| 40 | Ленин, 62 йорт | 1 | ** | 670 | 1675000,00 | 13508,06 | 2,00 | | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 13508,06 |
| 41 | Шәһәр чите, 8 йорт | 1 | ** | 540 | 1350000,00 | 28125,00 | 2,00 | | 1,00 | 0,50 | 0,50 | 14062,50 |
| 42 | Ленин, 39 йорт | 1 | ** | 1030 | 2575000,00 | 29941,86 | 1,00 | | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 14970,93 |
| 43 | К.Маркс, 53 йорт | 1 | **** | 432 | 1080000,00 | 15000,00 | 2,00 | | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 15000,00 |
| 44 | Ленин, 68 йорт | 1 | ** | 1725 | 4312500,00 | 30369,72 | 1,00 | | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 15184,86 |
| 45 | Союз, 6 йорт | 1 | * | 590 | 1475000,00 | 15364,58 | 2,00 | | 1,00 | 1,00 | 0,50 | 15364,58 |